КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 22 декабрь г.Казань № 1267

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багажлар ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 929 нчы карары белән расланган Җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багажлар ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багажлар ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 929 нчы карары белән расланган Җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багажлар ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәгә, VII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«VII. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) өчен төп күрсәткечләр һәм аларның максатчан мәгънәләре, индикатив күрсәткечләр

58. Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төп күрсәткече – 100 мең кешегә Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу аркасында җиңел такси белән идарә итүче машина

йөртүчеләрнең гаебе белән һәлак булган кешеләр санын киметү, кеше.

Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төп күрсәткеченең максатчан мәгънәсе – бу Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә Җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багажлар ташу өлкәсендә дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) һәм инвалидлар өчен җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багажлар ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итүне контрольдә тотуның төп күрсәткече паспорты күрсәткечен исәпләп чыгару өчен кулланыла торган үзгәрмәләрне исәпләп чыгару методикасы нигезендә 5 балл күрсәткеченә ирешү өлеше.

59. Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) индикатив күрсәткечләре:

1) хисап чорында план буенча үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

2) хисап чорында планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

3) хисап чорында контрольдә тотылучы объектның мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторларында расланган параметрларга туры килүен яки контрольдә тотылучы объектның мондый параметрлардан читкә китүен ачыклау нигезендә планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

4) хисап чорында контрольдә тотылучы зат белән хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны;

5) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларының һәр төре буенча контрольдә тотылучы зат белән хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

6) хисап чорында үзара дистанцион хезмәттәшлек итү чараларыннан файдаланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

7) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;

8) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында игълан ителгән кисәтүләр саны;

9) хисап чорында нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

10) хисап чорында йомгаклары буенча административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

12) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

13) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән һәм прокуратура органнары тарафыннан килештерелмәгән гаризалар саны;

14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы объектларның гомуми саны;

15) хисап чоры ахырына исәпкә алынган, риск категорияләренә кертелгән контрольдә тотылучы объектларның риск категорияләрендәге һәрберсе буенча саны;

16) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

17) хисап чорында исәпкә алынган һәм аларга карата контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән контрольдә тотылучы затлар саны;

18) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;

19) хисап чорында контрольдә тотучы орган тарафыннан карап тикшерү срогы бозылган шикаятьләр саны;

20) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән, карап тикшерү йомгаклары буенча контрольдә тотучы органның карарын тулысынча йә өлешчә гамәлдән чыгару турында яисә контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органнарның вазыйфаи затлары гамәлләрен (гамәл кылмавын) гамәлдән чыккан дип тану турында карар кабул ителгән шикаятьләр саны;

21) хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән дәгъва гаризалары саны;

22) хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән, белдерелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән дәгъва гаризалары саны;

23) хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозып үткәрелгән һәм нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) гамәлдән чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны.».

2. Бу карар 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин